**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

05.08.2019 № 265

**Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турында**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзалары үз вәкаләтләрен үтәүне вакыты җитмичә туктатулары сәбәпле, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 23 һәм 29 статьялары һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 12 һәм 18 статьялары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзалары итеп вакантлы ике урынга билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турындагы кушымтада бирелүче белдерү текстын расларга һәм аны «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсенә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары итеп билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны, 2019 елның 12 августыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентына бирергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе Ә.Ә. Сәфәровка йөкләргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 05 » августындагы
265 номерлы боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзалары итеп вакантлы ике урынга билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турында
белдерү

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең ике әгъзасы үз вәкаләтләрен үтәүне вакыты җитмичә туктатулары сәбәпле, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 23 һәм 29 статьялары һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 12 һәм 18 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган әгъзалары итеп вакантлы ике урынга билгеләп кую өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул ителә.

Тәкъдимнәр һәм аларга теркәп бирелүче, закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән документлар әлеге белдерү рәсми басылып чыккан көннән соң биш көн эчендә 9 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420014, Казан шәһәре, Кремль, 5 корпус, 203 кабинет, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты (Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе) (элемтә өчен телефон 8 (843) 567-89-95).